# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**15 ноябрь 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылында гражданнар җыены:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Кече Бортас авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизация буенча мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү;
- Традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27,
- ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Ленин ур., 70,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге
башлыгы Р. С. Сәгдиев